**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Күтәмә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге составына керүче Күтәмә авылы торак пунктында

**18 октябрь 2021 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге составына керүче Күтәмә авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2022 елда Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегенең Күтәмә торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:
2. Алынган чараларны җибәрергә:

- Күтәмә торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
- Күтәмә торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләргә түләү, запас частьләр сатып алу, асылмалы һәм тагылма җиһазлар сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнарына;
- Җәмәгать пространстволарын төзекләндерү һәм авыл территорияләрен үстерү буенча проект-смета документациясен әзерләүгә чыгымнар.

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге башлыгы С.Н. Хәйруллин